ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2019 г. Заинск № 15

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 1187 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»**

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 1187 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Сатып алулар өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән заказ бирүчеләрнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе турында Нигезләмә» карарының 1 нче кушымтасын яңа редакциядә расларга.

2) «Муниципаль контрактлар реестры турындагы нигезләмәне» карарның 4 нче кушымтада яңа редакциядә расларга;

3) «Контракт идарәчесенә боерык формасы, бурыч һәм җаваплылык» карарының 9 нчы кушымтасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Е.А. Улитина